КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 22 июнь г.Казань № 511

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 22 ноябрь, 910 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 22 ноябрь, 910 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 18 декабрь, 997 нче; 2015 ел, 17 апрель, 260 нчы; 2015 ел, 9 сентябрь, 659 нчы; 2015 ел, 8 октябрь, 753 нче; 2016 ел, 14 март, 139 нчы; 2016 ел, 26 октябрь, 785 нче; 2017 ел, 8 май, 264 нче; 2017 ел, 6 октябрь, 763 нче; 2017 ел, 20 октябрь, 799 нчы; 2018 ел, 4 май, 316 нчы; 2018 ел, 8 август, 647 нче; 2019 ел, 21 гыйнвар, 29 нчы; 2019 ел, 15 апрель, 291 нче; 2019 ел, 13 июль, 575 нче, 2019 ел, 15 ноябрь, 1042 нче, 2020 ел, 22 гыйнвар, 16 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «2014 – 2022» саннарын «2014 – 2023» саннарына алмаштырырга;

1 пунктта «2014 – 2022» саннарын «2014 – 2023» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган «2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү» дәүләт программасында (алга таба – Программа):

исемдә «2014 – 2022» саннарын «2014 – 2023» саннарына алмаштырырга;

Программа паспортында:

«Программасының исеме» юлында «2014 – 2022» саннарын «2014 – 2023» саннарына алмаштырырга;

«Программаны гамәлгә ашыру сроклары» юлында «2014 – 2022» саннарын «2014 – 2023» саннарына алмаштырырга;

«Еллар буенча бүленеп Программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар буенча бүленеп Программаны финанслау күләмнәре | Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән Программаны финанслауның гомуми күләме 380 426,98 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>2014 елда – 31 487,6 мең сум;<br>2015 елда – 30 987,08 мең сум;<br>2016 елда – 32 137,9 мең сум;<br>2017 елда – 56 504,6 мең сум;<br>2018 елда – 37 735,0 мең сум;<br>2019 елда – 47 969,95 мең сум;<br>2020 елда – 36 849,85 мең сум;<br>2021 елда – 35 585,0 мең сум;<br>2022 елда – 35 585,0 мең сум;<br>2023 елда – 35 585,0 мең сум»; |

"Программаны тормышка ашыруның көтелгән соңгы нәтиҗәләре» юлның беренче абзацында «2022 елга» сүзләрен «2023 елга» сүзләренә алмаштырырга;

Программаның II бүлегендәге уникенче абзацында «2014 – 2022» саннарын «2014 – 2023» саннарына алмаштырырга;

Программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. Программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Программа чаралары Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән тормышка ашырыла. Программаны 2014 – 2023 елларга финанслауның гомуми күләме 380 426,98 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:

2014 елда – 31 487,6 мең сум;
2015 елда – 30 987,08 мең сум;
2016 елда – 32 137,9 мең сум;
2017 елда – 56 504,6 мең сум;
2018 елда – 37 735,0 мең сум;
2019 елда – 47 969,95 мең сум;
2020 елда – 36 849,85 мең сум;
2021 елда – 35 585,0 мең сум;
2022 елда – 35 585,0 мең сум;
2023 елда – 35 585,0 мең сум.

Бюджет мөмкинлекләрен исәпкә алып, Программаны гамәлгә ашыруга юнәлдерелә торган акчалар күләме чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты проектын эшләгәндә аныклана.

Программаның V бүлегендәге тугызынчы абзацта «2022 елга» сүзләрен «2023 елга» сүзләренә алмаштырырга;

Программага 1 нче һәм 2 нче кушымталарны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин